ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА УРУССУ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
423950, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы,
Пушкин урамы, 38

Тел.: 8(85593)2-92-40, факс: 2-61-50, e-mail: Pgt.Urussu@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 22 » 11 2018г. № 34

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе” муниципаль берәмлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю Тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федраль законга, 2004 елның 24 мартындагы «Җирле референдум турында»гы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе” муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы, 2018 елның 18 ноябрендә уздырылган җирле референдумда кабул ителгән №95 карарны гамәлгә ашыру максатыннан, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар итә:

1.Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе гражданнарының үзара салым акчаларын җыюның кушымтадагы Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны “Ютазы таңы”-“Ютазинская новь” район газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы jutaza.tatar.ru рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Башкарма комитет
җитәкчесе вазифаларын башкаручы З.Н. Айтыкина

Т.Г.Исмәгыйлова
2-92-40

шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе
Башкарма комитетының 2018
елның 22.11. № 34 карарына

**_Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1.Әлеге Тәртип шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 18 яшькә җиткән һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе территориясендә теркәлгән гражданнар тарафыннан 2018 елның 31 мартына кадәр, аларның җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашу-катнашмавына һәм аларның тавыш бирү барышында белдергән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә түләнә.

3. Үзара салым акчасын түләүдән гражданнарның түбәндәге категорияләре азат ителә:

а) Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларга тиңләштерелгән затлар;

б) 1,2 төркем инвалидлары, балачактан инвалидлар.

4. Гражданнарның аерым категорияләренә:

көндезге бүлектә укыган студентларга түләү күләме җирле референдум (гражданнар җыены) карарында билгеләнгән сумманың (50) процентын, 150 сум тәшкил итә.

5. Бер тапкыр түләнә торган түләүне башкару турындагы белдерү кәгазе (уведомление) бланкы гражданнар игътибарына Ютазы муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру, мәгълүмати стендларга куеп халыкка җиткерү,, шулай ук имза куйдырып шәхсән тапшыру яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән җиткерелә.

Белдерү кәгазе үз эченә гражданнарның үзара салым акчаларын күчерү реквизитларын, бер тапкыр түләнә торган акчаның тулысынча яки киметелгән күләмдәге суммасын, түләү вакытын алырга тиеш.

6. Гражданнардан алынган үзара салым акчалары ТР ФКИ (Ютазы муниципаль районы финанс-бюджет палатасы) шәхси счетына керә.

7. Түләүләрне башкару гражданнар тарафыннан акчаларны физик затлар теләге буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру, акчаларны почта аша күчерү (исәп-хисап оешмалары), шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе башкарма комитеты кассасы аша күчерү хокукына ия булган оешма аша күчерү яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү хокукына ия булган оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

8. Түләү фактын раслау булып, керү-касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

9. Гражданнарның билгеләнгән срокта күчерелмәгән үзара салым акчалары закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Кушымта 2
Шәһәр тибындагы Урыссу
бистәсе Башкарма комитетының
2018 елның 22.11 -№ 34
карарына

Ютазы муниципаль районы шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләү кертү турында

БЕЛДЕРҮ КӘГАЗЕ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № ___

Түләүченең Ф.И.Ә.и.______________________________________________
Адрес:
_____________________________________________________________
Нигезләмә ___________________________________________________
Сезгә ________________________ көнгә кадәрге вакыт эчендә
____________________________________________________ чараларны гамәлгә
ашыру буенча ______________ сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган түләүне түбәндәге реквизитларга күчерергә кирәк:
Банк получателя БИК 049205001
Сч. № 401 018 108 000 000 1 000 1
Банк: Отделение-НБ Республика Татарстан, г.Казань
ИНН 1642004459
КПП 164201001
КБК 802 117 14030 13 0000 154
ОКАТО 92654151
Назначение платежа
Самообложение за 2019г.
Руководитель ___________________________________________________
М.П. (подпись) (расшифровка подписи)

- - - - - - - - - - - - - - - - - **кисеп алу сызыгы** - - - - - - - - - - - - - -

Ютазы муниципаль районы шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне ________________ сум күләмендә түләү турында № ________ белдерү кәгазе (уведомление).
Түләүченең Ф.И.Ә.и.
_______________________________________________________
Адрес: ________________________________________________________
Кабул ителде «__» _______________ 20__ ел.
_____________________________________
(түләүченең имзасы)
*Искәрмә. Белдерү кәгазе түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, түләү кәгазе өлеше (отрывной корешок) тутырыла һәм шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе башкарма комитетында кала.*